ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21 04 2020 г. № 253

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 332 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 332 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

«Аяк киеме ремонтлау буенча киосклар» бүлегендә 2 пунктта «Характеристика (җир кишәрлегенең кадастр №)» баганасында «мәйданы 7 кв.м» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Аяк киеме ремонтлау буенча киосклар» бүлегендә 3, 10, 11, 19, 22 пунктларны төшереп калдырырга;

«Сәүдә павильоннары» бүлегендә 7, 15, 18, 19, 20, 21, 22, 25, 41, 42, 43, 44, 45, 54, 60, 61, 62, 63 пунктларны төшереп калдырырга;

«Җәмәгать туклануы предприятиеләре» бүлегендә 5, 6, 7 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. И. Беляевка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкченең беренче урынбасары Р.И. Беляев